***Максат: Балаларны авыр сугыш чоры михнәтләре белән таныштыру, ватаныбыз тарихына карата кызыксыну формалаштыру, ветераннарга хөрмәт, фашизмга нәфрәт тәрбияләү.***

**Бәхетле бул, балам! Җирдә яңа кеше туа һәм якты дөнья белән исәнләшкәндәй, беренче тапкыр кычкырып аваз сала. Бәхетеннән чиксез шатланган ана, елмаеп нәни сабыена төбәлә һәм әкрен генә әлеге сүзләрне кабатлый:**

**"Син дөньяга килдең, син бәхетле,**
**илебезнең киләчәге синең кулда....."**

**Әйе, һәр ана үз сабыена зур өмет белән ышанып карый. Ана үз баласын туган көннән алып, күкрәк сөтен имезеп, җан җылысын биреп, иркәләп, назлап үстерә.**

**"Бәхетле бул, балам," дип кайсы гына ана үз баласына әйтмәгәндер?**

**1941 елның 22 июнендә шушы мәхәббәтне, назны, сөюне явыз фашистлар таптап, аналарыбызның йөрәгенә әрнү – сагыш салып, балаларның якты, бәхетле балачагын урлап сугыш – дәһшәтле бөек ватан сугышы башлана.**
**1941 – 1945 еллар тарих битләренә канлы хәрефләр белән уелган.**
**бөек ватан сугышы егерменче гасырның иң олы фаҗигасы.**
**җимерелгән кала – авыллар, аяусыз бәрелешләр, киселгән гомерләр, ятимнәрнең ачы күз яшләре....**
**сугыш ул – бик куркыныч нәрсә,**


**кан ул – ут ул, үлем, яралар,**

**күз яшьләре, ачлык, кайгы**

**тол аналар, ятим балалар.**

Кадерле китап укучыларыбыз!

Без , сезне белорус язучысы
Елена Кобец Филимонованың “Хатынь тургайлары” дигән китабы белән таныштырырга телибез.
Бу китап – Белоруссиядәге  Хатынь кешеләре турында җанлы һәм чын хикәя, бу урман авылының инде беркайчан да олы кеше була алмаган балалары турында. Фашистларның акылга сыймаслык кансызлыгы, Хатынь авылының коточкыч фаҗигасе турында.




Бу күренешкә тын бетә....
Һәм көтмәгәндә шул мизгелдә
Үткен чыңнары белән
Йөрәкләрне телеп үтәдән – үтә
Кайдадыр биектә
Көмеш тавышлы, кыңгыраулар чыңлый башлады:
Тиңгел – тиңгел! Чәңгел – чеңгел!
Бу төтен ялаган, сөремләнеп каралып
Беткән мич моржаларына
Куелган кыңгырайлар чыңлый икән шулай.
Әнә бер кыңгырай тыңарга өлгермәде,
Аңа икенчесе, өченчесе....
Җиденчесе... Уникенчесе кушылып китте.
Кыңгыраулар чыңлый һәр мич моржасында
Тик аларның һәрберсе сагыш, хәсрәт җырчысына!
Бу әрнүне, бу хәсрәтне бөтен җиһан
Тыңлый сыман....
Биредә Хатынь исемле авыл булган
Аның тирә – ягында ак каеннар шаулап торган
Хәзер инде ул авыл түгел – зират.


… Дүшәнбе көн иде.

Карт – коры яз җитүгә шатланган, каен бөреләре бүртенеп тулышкан, авылда кар бетеп, коры җирләр күренә башлаган көннәр иде. Бары тик урманда гына бераз көпшәк кар калган. Кошлар өздереп сайрый, һавада эрегән нарат сагызы исе аңкый.

Эсэсчылар, минометларын, танкка каршы ата торган тупларын төягән саргылт – яшел йөк машиналарында чайкала – чайкала Хатыньга якынлаштылар. Офицерлары, сиздерми генә авылны чолгап алырга боерык бирде. Яшел һәм кара шинельләр урманга сибелеп Хатыньга якынлаша башладылар.




Немецларның җәза отряды бар авыл халкын өйләреннән куып чыгарып, буш сарайга ябып, барлык йортларга, халыкны япкан сарайга бензин сибеп ут төрттеләр. Алар беркемне дә кызганмадылар. Дөрләп янган сарай ишеге дистәләгән гәүдәнең басымына түзә алмыйча җимерелеп төште. Үзләре дә факел кебек дөрләп янган кешеләр, котылу эзләп, ташкын кебек тышка ыргылдылар. Тик анда аларны адәм кыяфәтле ерткычлар пулемет уты белән каршы алдылар.



Шылт иткән тавыш юк,
Тик җилләр йөренә.
Янган йорт янында
Бер тавычык күренә.
Якынрак килсәләр,
Бар да тын кала:
Атылган балалар....


Тибрәнә җилләрдә
Мамыктай чәчләре....







**Сарайда 9 балалары белән Анна һәм Йосиф Барановскийлар (уллары Антон исән кала) һәм 7 шәр балалы Александра һәм Александр Новицкийлар, Елена һәм Казимир Нотколар (иң кечкенә балаларына 1 яшь) янды. Тагын бик күп гаиләләр янды. Бу гаиләләрнең, сабыйларның гаебе нәрсә дә соң???**



Хатынь трагедиясенең бердәнбер исән калган өлкән шаһиты – 56 яшьлек авыл тимерчесе Йосиф Каминский була. Ул яраланган, янган килеш авылдашларының мәетләре арасыннан улы Адамнытаба. Улы әтисенең кулында җан бирә. Йосиф Каминскийның тормышындагы менә шушы трагик мизгел “Хатынь” мемориаль комплексындагы бердәнбер скульптураның нигезенә салынган. Ул “Буйсынмас кеше” дип атала.

......Кечкенә Адасик фаҗига булырга 1 көн кала төш күрә: имеш тургайга әверелеп күккә ашкан да очып киткән......



....Янган хәрабәләр янына көндә килә Йосиф Каминский. Янган бүрәнәләргә утыра да уйга тала. Ә күктә тургайлар талпына – талпына яңгыратып сайрыйлар. Нәрсә турында сайрый соң алар? Менә берсе картның янына ук килде, баш очында җилпенеп, аңа нидер сөйләгәндәй булды. Бу кошка карап карт: “бәлки, шушыдыр әле минем Адасигым?” дип уйлады. Ә кош кайгыдан саргайган ялгыз картны юатырга тели сыман.

- Әйе, әйе, бу минем тургайчыгым...бу ул...минем улым...- дип уйлый карт эченнән генә, һәм аның күзләренә томан булып яшь сара.




Бер гаебе булмаган 149 кеше, шуларның 75е - 16 яшькә дә җитмәгән бала, дәһшәтле утта янып көлгә әверелде. Уй – фигыльләре, гадәтләре, холыклары төрле – төрле булган бу 149 кешене бер үк язмыш берләштерә, алар хакында мәңгелек хәтирә генә кала. Гөрләп торган Хатынь урынында, элекке 26 йорт урынына 26 морҗа гына тырпаеп калды.

Фашистлар авылны
яндырып киткәннәр.
Кардай ак өйләрне
хәрабә иткәннәр.
Каралган агачлар,
йортлар көл булганнар.
Бары тик морҗалар
тырпаеп калганнар.


**Сугыш чорында нигезенә кадәр яндырылган 186 авылның изге туфрагы Хатыньга китерелгән. Бүгенге үле Хатынь – авыллар каберлеге ул.**

**Күреп ничек өзелмәсен кешеләрнең бәгырьләре**
**Бар белорус туфрагында авылларның каберләре.**
**Татыган бар бу дөньяның ләззәтләрен, әрүләрен,**
**Тик гомердә башлап күрәм авылларның каберләре...**

# Чаң – чоң!

Чаң – чоң!
Янгыннан соң инде күпме еллар үтте. Һәйкәл – Хатынь урманнары өстендә чаңнар чыңлый да чыңлый.
Чаң – чоң!
Чыңнар төрле була. Ә бу – Хатынь чыңы! Ул бөтен дөньяга ишетелә. Коточкыч газаплардан үлгәннәрнең истәлегенә зурлап баш ию өчен кешеләр монда ераклардан киләләр.
Чаң – чоң!!!





Кем генә булсаң да син, Хатыньга барсаң, кабер ташына чәчәк куярга онытма. Үзең бераз утырып тор, ерак юлдан соң ял ит, һәм күк йөзенә кара, тургайларны тыңла. Бел, Хатынь тургайлары башка җирдәге тургайлар төсле сайрамыйлар. Нәрсә турында сөйли алар?... Ә син тыңла, уйла һәм шунда йөрәгең белән аларның җырын ишетерсең:

“Кешеләр, исегездә тотыгыз: без тормышны, Ватаныбызны, сезне яраттык, кадерле кешеләр. Без сездән үтенеп сорыйбыз, кешеләр: җирдә мәңге тынычлык һәм иминлек булсын өчен көчегезне кызганмагыз. Моннан соң беркайчан да һәм бервакытта да ут өермәләре кабынмасын, тормыш үлмәсен!


Шәфкатьле кешеләр, соны хәтерегездән чыгармагыз!

Безне онытмагыз! ... Онытмагыз!....

Хатынь фаҗигасе һәрчак хәтерегездә булсын!

Толларның күзендә,
Ятимнәр йөзендә
Сугышның шәүләсе бар һаман.
Күңелә шом яши,
Җәен дә җан өши –
Сугышлар булмасмы яңадан?
Яз – көзләр өр – яңа гөлләрдә,
Тик толлар күзеннән
Ятимнәр йөзеннән
Сугышның шәүләсе бетәрме?

ALLDAY.RU


Һәр елны, 22 март көнендә. кешеләр Хатыньга
килә. Бу көн -  Хатынь фаҗигасе көне.
22 март – Хатынь корбаннарын искә алу көне ул.

# <u>Китап сөюче укучы балалар!</u>

**Без сезгә, балалар китапханәсендә, сугыш чоры балаларына багышланган түбәндәге әдәбиятны укырга тәкъдим итәбез.**




1. Дети – герои Великой Отечественной войны. – М. Дрофа-плюс - 2007.
2. Дәһшәтле чор балалары. – 15 томда. Т. 7.- Казан: Тат. кит. нәшр.,2010.
3. Сугыш чоры балалар әдәбияты.- 15 томда. Т 4. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2010.
4. Катаев. В. Сын полка. – Сыктывкар: Коми кн. изд-во, 1982.
5. Герой – пионерлар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – 320б.
6. Была война. Рассказы. – М.: Детская литература, 1978.
7. Мәһдиев М. Кеше китә, җыры кала: хикәя һәм повестьлар. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1979.
8. Адамиович А. Хатынская повесть. Каратели. – М. Советский писатель, 1984. – 416с.
9. Бровка П. Пишу о сердце человечьем.. Сборник. Пер.с белорус. – М.: “Молодая гвардия”, 1974.
10. Кәрим Ф. Илең турында уйла: Шигырьләр, поэмалар, балладалар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1989.
11. Җәлил М. Кечкенә дусларга: шигырьләр.-Казан: Тат. кит. нәшр.,1989.
12. Кобец – Филимонова Е. Хатынь тургайлары. – М.: Детская лит-ра,1973.

# **КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ**.


1. **КОБЕЦ - ФИЛИМОНОВА Е. ХАТЫНЬ ТУРГАЙЛАРЫ. – М. “ДЕТСКАЯ ЛИТЕРАТУРА”. – 1973.**

2. **ПИОНЕР СӘХНӘСЕ . 6 КИТАП. – КАЗАН: ТАТ. КИТ. НӘШР. - 1978.**

3. **ПИОНЕР СӘХНӘСЕ. 8 КИТАП. – КАЗАН: ТАТ. КИТ. НӘШР., - 1987. .**

4. **АДАМОВИЧ. А. ХАТЫНСКАЯ ТРАГЕДИЯ. КАРАТЕЛИ. – М.: СОВЕТСКИЙ ПИСАТЕЛЬ – 1984.**

5. **ИНТЕРНЕТТАН МАТЕРИАЛЛАР, ФОТОЛАР.**